**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

---

**2022елның 10 октябре** **80-РС номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Урта Девятово авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында.**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2019 елның 12 декабрендәге 96-РС номерлы карары расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2018 елның 12 декабрендәге 61-РС үзгәрешләр белән расланган «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында. нигезләмәгә таянып, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хокук ияләренең уңай яшәү шартларына, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында Лаеш муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы районы Урта Девятово авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә;

2. Ачык тыңлаулар үткәрү чорын - кызыксынган затларга аларны үткәрү турында хәбәр итү вакытыннан гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә бастырылган көнгә кадәр дип билгеләргә. Ачык тыңлауларны үткәрү вакыты бер айдан да ким өч айдан артык булмаска тиеш;

3. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты:

3.1. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясында каралган Иҗтимагый фикер алышулар башлану турында хәбәрнамә әзерләргә;

3.2. Әлеге карар үз көченә кергән көннән 14 эш көне эчендә әлеге карарның 3.1.1 пунктында күрсәтелгән хәбәрнамәне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы уставында билгеләнгән тәртип нигезендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә);

3.3. Әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән чорда ачык тыңлаулар үткәрергә;

3.4. Ачык тыңлаулар тәмамланганнан соң 5 көн эчендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Урта Девятово авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын, ачык тыңлаулар беркетмәсен һәм ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында

бәяләмәне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советына ахыргы карар кабул итү өчен җибәрергә.

4. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә)..

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары И. П. Шитовка йөкләнә.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы Рәисе** **И.Ф. Зарипов**